ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## “Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 маенда
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында” 2004 елның 6 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2011 елның 10 октябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 6; 2011, № 10 (I өлеш); 2013, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 3 пунктында “озак сроклы максатчан” сүзләрен “дәүләт” сүзенә алмаштырырга;

2) 9 статьяның 1 өлешендә “ата-аналары һәм балалары” сүзләрен “ата-аналары, балалары һәм балаларының ире яисә хатыны” сүзләренә алмаштырырга;

3) 13 статьяның 1 өлешендәге 10 пунктында “озак сроклы максатчан” сүзләрен “дәүләт” сүзенә алмаштырырга;

4) 14 статьяда:
а) исемендә “һәм муниципаль” сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 1 өлештә “һәм муниципаль” сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 19 статьяның 2 өлешендә “Хисап палатасы Регламентында билгеләнгән тәртиптә” сүзләрен “әлеге Законга кушымта нигезендәге рәвеш буенча” сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Язма хәбәрне билгеләнгән вакытта тапшыру мөмкинлеге булмаган очракта, Хисап палатасы Рәисенә мөмкин булган башка алым белән хәбәр ителә, аннан соң язмача хәбәр җибәрелә.”;

6) 26 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктында “озак сроклы максатчан программалар” сүзләрен “дәүләт программалары” сүзләренә алмаштырырга;

7) 32 статьяның 6 өлешендәге 3 пунктында “хезмәткәрләренә һөнәри әзерлек, яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү буенча” сүзләрен “хезмәткәрләренең һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем алуына” сүзләренә алмаштырырга.

8) түбәндәге эчтәлекле кушымта өстәргә:

“Татарстан Республикасы
Хисап палатасы турында”
Татарстан Республикасы
Законына кушымта

Татарстан Республикасы Хисап палатасы
Рәисенә ____________________________
____________________________________
(Рәиснең фамилиясе, инициаллары)

**Кассаларны, касса һәм хезмәт биналарын,
складларны һәм архивларны мөһерләп бикләп
кую, документларны һәм материалларны тартып алу турында
ХӘБӘРНАМӘ**

Сезгә______________________________________________________________ карата
(тикшерелүче орган яисә оешма исеме һәм адресы)
____________________________________________________ контроль чарасы уздырганда
(контроль чарасы исеме)
“Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында” Татарстан Республикасы Законының 19 статьясындагы 2 өлеше нигезендә ______________________________________
(Татарстан Республикасы Хисап палатасы вазыйфаи затының
__________________________________________________________________________
вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары)
__________________________________________________________________________
тарафыннан түбәндәгеләрне мөһерләп бикләп кую (тартып алу) турында хәбәр итәм:
__________________________________________________________________________
(мөһерләнеп бикләп куелган объектлар, алынган документлар һәм материаллар исемлеге)

Мөһерләп бикләп кую (тартып алу) вазыйфаи зат ______________________________
(вазыйфасы, тикшерелүче орган яисә оешма
__________________________________________________________________________
исеме, тикшерелүче орган яисә оешманың, вазыйфаи затының фамилиясе, инициаллары)
____________________________________________________ катнашында башкарылды.

Объектларны мөһерләп бикләп кую (документларны һәм материалларны тартып алу) факты буенча акт (актлар) төзелде, __ биттә __ нөсхәдә күчермәсе (күчермәләре) кушымта итеп бирелә.
"_____" сәг. "____" мин.
20___ елның "___" __________________ ______________________________________________
(Татарстан Республикасы Хисап палатасы вазыйфаи затының шәхси имзасы, фамилиясе, инициаллары)"

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 9 июне
№ 44-ТРЗ